КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 гыйнвар г.Казань № 15

Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки аларны реиндустриализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен хосусый милек рәвешендәге индустриаль (сәнәгать) паркларның, сәнәгать технопаркларының, югары технологияләр өлкәсендәге техно-паркларның идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәнәгатьне үстерү һәм аның конкуренциягә сәләтен арттыру» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 328 номерлы карары белән расланган «Сәнәгатьне үстерү һәм аның конкуренциягә сәләтен арттыру» Россия Федерациясе дәүләт программасына 18 нче кушымтада китерелгән Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки аларны реиндустриализацияләү буенча шәхси милек рәвешендәге индустриаль (сәнәгать) паркларның, сәнәгать технопаркларының, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләре чыгымнарының бер өлешен каплау буенча Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр

рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 ел, 25 октябрь, 1782 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки аларны реиндустриализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен хосусый милек рәвешендәге индустриаль (сәнәгать) паркларның, сәнәгать технопаркларының, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 16 гыйнвар, 15 нче
карары белән расланды

# Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки аларны реиндустриализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен хосусый милек рәвшендәге индустриаль (сәнәгать) паркларның, сәнәгать технопаркларының, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәнәгатьне үстерү һәм аның конкуренциягә сәләтен арттыру» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 328 номерлы карары белән расланган «Сәнәгатьне үстерү һәм аның конкуренциягә сәләтен арттыру» Россия Федерациясе дәүләт программасына 18 нче кушымтада китерелгән Шәхси милек рәвешендәге индустриаль (сәнәгать) паркларның, сәнәгать технопаркларының, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренең индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки аларны реиндустриализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау буенча Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары нигезендә эшләнде һәм парклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки аларны реиндустриализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен хосусый милек рәвшендәге индустриаль (сәнәгать) паркларның, сәнәгать технопаркларының, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар Кагыйдәләрдә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләре турында» 2015 елның 4 августындагы 794 номерлы карарында (алга таба – 794 номерлы карар), «Сәнәгать технопарклары һәм сәнәгать технопаркларының идарәче компанияләре турында» 2019 елның 27 декабрендәге 1863 номерлы карарында (алга таба – 1863 номерлы карар), «Югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләре турында» 2023 елның 25 августындагы 1381 номерлы карарында (алга таба – 1381 номерлы карар) билгеләнгән мәгънәләрдәге кебек мәгънәләрдә кулланыла.

1.3. Субсидияләр бирү максаты – идарәче компанияләр тарафыннан парклар төзүгә, аларның мәйданын арттыруга яки аларны реиндустриализацияләүгә сарыф ителгән, фактта башкарылган һәм документ белән расланган чыгымнарның бер өлешен каплау.

1.4. Субсидия әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына һәм план чорына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

1.5. Субсидия, Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – Россия Сәнәгать министрлыгы) тарафыннан Кагыйдәләр нигезендә Россия Сәнәгать министрлыгы үткәрә торган федераль сайлап алу (алга таба – федераль сайлап алу) нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы белән федераль бюджеттан субсидия бирү турында килешү төзү хакында карар кабул ителгән очракта бирелә.

Субсидияне финанс белән тәэмин итү чыганагы – идарәче компанияләрнең парклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки реиндустриализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидия акчасы.

1.6. Субсидияләр турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

## II. Идарәче компаниягә карата таләпләр һәм субсидия бирү шартлары

2.1. Субсидия алу өчен идарәче компания әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә субсидия алу өчен документлар тапшырган календарь кварталдагы беренче айның 1нче көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

идарәче компаниянең бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмый яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

идарәче компаниянең чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компания-ләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

идарәче компания экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

идарәче компания Берләшкән Милләт Оешмасы (алга таба – БМО) уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркыныч-сызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

идарәче компания әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

идарәче компания «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген кон-трольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

идарәче компаниянең башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

идарәче компания үзгәртеп оештыру (идарәче компаниягә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмый, аңа карата банкротлык процессы билгеләнми, идарәче компания эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмый;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки идарәче компаниянең баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмый.

Әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән таләпкә идарәче компаниянең туры килү-килмәве Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 241 статьясындагы 15 пункты нигезләмәләренең Россия юридик затларына бирелә торган субсидияләргә һәм бюджет инвестицияләренә кагылмавы турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2024 елның 17 июнендәге 813 номерлы карары нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә.»;

2.2. Субсидия бирү шартлары:

парк төзү, аның мәйданын арттыру яки аны реиндустриализацияләү проекты федераль сайлап алудан узу;

Министрлык һәм идарәче компания арасында Кагыйдәләр нигезендә төзелгән инвестиция меморандумы булу;

идарәче компания Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара һәм Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салымнар түли;

794 номерлы карар нигезендә индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләре реестрында парк һәм идарәче компания булу (индустриаль (сәнәгать) парк проектын гамәлгә ашырганда);

1863 номерлы карар нигезендә сәнәгать технопарклары һәм сәнәгать технопаркларының идарәче компанияләре реестрында парк һәм идарәче компания булу (сәнәгать технопаркы проектын гамәлгә ашырганда);

1381 номерлы карар нигезендә югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләре реестрында парк һәм идарәче компания булу (югары технологияләр өлкәсендәге технопарк проектын гамәлгә ашырганда);

парк инфраструктурасы объектларының проект-смета документациясенә, төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләүгә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе булу;

парк инфраструктурасы объектларын файдалануга тапшыру турында, төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләүгә акт булу;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документларын һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм уздыру тәртибе турында» 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары нигезендә парк инфраструктурасы объектларының смета кыйммәтен билгеләү дөреслеге турында, төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләүгә уңай бәяләмә булу;

идарәче компания Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт яки муниципаль учреждениеләр тарафыннан гамәлгә куелган (алар катнашкан) оешма булып тормый.

## III. Субсидия алу өчен документлар

3.1. Субсидия алу өчен идарәче компания Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) ел саен, субсидияләр бирелә торган һәр елның беренче аендагы 15нче көненнән дә соңга калмыйча, түбәндәге документлар (алга таба – ел саен бирелә торган заявка):

Министрлык акты тарафыннан раслана торган форма буенча субсидиянең сорала торган күләме күрсәтелгән субсидия алуга заявка;

Министрлык акты белән раслана торган форма буенча субсидияләр күләме фаразы (кварталлар буенча бүлеп);

парк инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү өчен идарәче компания акчасын агымдагы финанс елына субсидия күләме исәпләнгән күләмдә файдалану сурәтләнгән аңлатма язуы;

парк резидентлары реестры;

идарәче компания җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

идарәче компаниянең гамәлгә кую документларының расланган күчермәләре (үзгәрешләр белән);

әлеге пунктча нигезендә документлар бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган өземтә яисә Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтындагы Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмә;

индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләре реестрыннан өземтә (индустриаль (сәнәгать) парк проектын гамәлгә ашырганда);

сәнәгать технопарклары һәм сәнәгать технопаркларының идарәче компанияләре реестрыннан өземтә (сәнәгать технопаркы проектын гамәлгә ашырганда);

югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар һәм югары технологияләр өлкәсендәге идарәче компанияләр реестрыннан өземтә (югары технологияләр өлкәсендәге технопарк проектын гамәлгә ашырганда);

идарәче компания балансында төзелгән (реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән) парк инфраструктурасы объектлары булуны раслый торган документлар күчермәләре;

парк инфраструктурасы объектларын төзүгә проект-смета документациясе күчермәсе;

дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе белән расланган парк инфраструктурасын төзү кыйммәтенең җыелма смета исәп-хисаплары күчермәләре;

парк инфраструктурасы объектларының проект-смета документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәләре;

парк инфраструктурасы объектларының смета кыйммәтен билгеләү дөреслеге турында уңай бәяләмәләр күчермәләре;

парк инфраструктурасы объектларын файдалануга тапшыру турында актлар күчермәләре;

парк инфраструктурасын төзү өчен подряд оешмасы белән төзелгән шартнамәләр, контрактлар, килешүләр күчермәләре;

парк инфраструктурасын төзү буенча башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү документлары күчермәләре;

КС-2 формасы буенча парк инфраструктурасын төзү өчен башкарылган эшләрне кабул итү турында актлар күчермәләре;

КС-3 формасы буенча парк инфраструктурасын төзү өчен башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә кәгазьләре күчермәләре;

паркның капиталь төзелеш объектлары төзелеше (реконструкциясе) бетүне раслый торган документлар күчермәләре (КС-11 яки КС-14 нче бертип форма буенча төзелеше төгәлләнгән объектны кабул итү актлары күчермәләрен, файдалануга тапшыруга рөхсәтнамәләр күчермәләрен, файдалануга тапшыру турында боерыклар

күчермәләрен кертеп);

дәүләт төзелеш күзәтчелеге органнарының (әгәр дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру каралган булса) парк инфраструктурасыдагы төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының техник регламентлар һәм проект документациясе таләпләренә туры килүе турындагы бәяләмәләре күчермәләре (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 7 өлешендә каралган очракларда);

техник күзәтчелек органының парк инфраструктурасы объектын файдалануга рөхсәт бирүгә рөхсәтнамәләре күчермәләре (булганда).

Әлеге Тәртипнең 5.2 пунктындагы өченче абзацы нигезендә идарәче компания тарафыннан сәнәгать технопаркының, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның технологик инфраструктурасы составында җиһаз сатып алуга сарыф ителгән чыгымнарны каплауга субсидия алу өчен идарәче компания тарафыннан ел саен бирелә торган заявка бирелгән очракта, әлеге пунктчаның икенче – егерме дүртенче абзацларында санап үтелгән документларга өстәмә итеп, идарәче компания Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

универсаль тапшыру документы формасы буенча җиһазны кабул итү-тапшыру турында актлар күчермәләре;

сатып алынган җиһаз өчен түләүне раслый торган түләү документлары һәм (яки) башка документлар күчермәләре.

Әлеге Тәртипнең 5.2 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә идарәче компания тарафыннан парклар инфраструктурасы объектларын проектлауга сарыф ителгән чыгымнарны (проект документациясен эшләү, аңа һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү, паркның капиталь төзелеш объектларын төзүнең, модернизацияләүнең һәм (яки) реконструкцияләүнең смета кыйммәтен билгеләүгә дәүләт экспертизасын үткәрү чыгымнарын кертеп) каплауга субсидия алу өчен идарәче компания тарафыннан ел саен бирелә торган заявка бирелгән очракта, әлеге пунктчаның икенче – егерме дүртенче абзацларында санап үтелгән документларга өстәмә итеп, идарәче компания Министрлыкка проект документациясен эшләү, аңа һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү, паркның капиталь төзелеш объектларын төзүнең, модернизацияләүнең һәм (яки) реконструкцияләүнең смета кыйммәтен билгеләүгә дәүләт экспертизасын үткәрү турында шартнамәләр күчермәләрен, мондый шартнамәләр буенча башкарылган эшләр турында актлар күчермәләрен, шулай ук башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү документлары күчермәләрен тапшыра.

Әлеге Тәртипнең 5.2 пунктындагы бишенче абзацы нигезендә идарәче компания тарафыннан парк инфраструктурасы объектларының техник шартларын эшләүгә һәм (яки) аларны инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә технологик тоташтыруга сарыф ителгән чыгымнарны каплауга субсидия алу өчен идарәче компания тарафыннан ел саен бирелә торган заявка бирелгән очракта, әлеге пунктчаның икенче – егерме дүртенче абзацларында санап үтелгән документларга өстәмә итеп, идарәче компания Министрлыкка парк инфраструктурасы объектларын электр белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, су чыгару, җылылык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү челтәрләренә технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында

шартнамәләр күчермәләрен, мондый шартнамәләр буенча башкарылган эшләр турында актлар күчермәләрен, шулай ук башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү документлары күчермәләрен, вәкаләтле техник күзәтчелек органының энергия җайланмасын файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү өчен рөхсәтнамәләре күчермәләрен тапшыра.

Идарәче компания Министрлыкка әлеге пунктчаның унөченче абзацында күрсәтелгән документны электрон мәгълүмат җайланмасында сканерланган рәвештә тапшырырга хокуклы.

Идарәче компания тарафыннан сигезенче – унберенче абзацларда күрсәтелгән документлар тапшырылмаганда, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә түбәндәгеләрне соратып ала;

б) агымдагы финанс елының календарь кварталындагы икенче айның 10нчы көненнән дә соңга калмыйча, квартал саен түбәндәге документларны (алга таба – квартал саен бирелә торган заявка):

Министрлык акты тарафыннан раслана торган форма буенча, субсидиянең сорала торган күләмен күрсәтеп, субсидия алуга заявка;

агымдагы финанс елының ахырына кадәр парк резидентлары тарафыннан түләнелә торган федераль салымнар һәм таможня пошлиналары суммаларының фараз күрсәткечләре турында белешмә кәгазе;

әлеге пунктча нигезендә квартал саен бирелә торган заявка бирелгән календарь кварталның беренче аендагы 1нче көненә идарәче компаниянең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмау турында салым органының белешмә кәгазе (алга таба – салым органының белешмә кәгазе);

идарәче компаниянең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имза куелган, әлеге пунктча нигезендә квартал саен бирелә торган заявка бирелгән календарь кварталның беренче аендагы 1нче көненә идарәче компаниянең башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш) булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

идарәче компаниянең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имза куелган, әлеге пунктча нигезендә квартал саен бирелә торган заявка бирелгән календарь кварталның беренче аендагы 1нче көненә идарәче компаниянең чит ил юридик заты, шул исәптән офшор компаниясе, шулай ук, әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы унберенче абзацын исәпкә алып, устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) катнашу өлеше, җыеп алганда, 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр башкасы Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса) булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

идарәче компаниянең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имза куелган, әлеге пунктча нигезендә квартал саен бирелә торган заявка бирелгән календарь кварталның беренче аендагы 1нче көненә идарәче компаниянең

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормавын раслый торган белешмә кәгазе;

идарәче компаниянең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имза куелган, әлеге пунктча нигезендә квартал саен бирелә торган заявка бирелгән календарь кварталның беренче аендагы 1нче көненә идарәче компаниянең БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормавын раслый торган белешмә кәгазе;

идарәче компаниянең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имза куелган, әлеге пунктча нигезендә квартал саен бирелә торган заявка бирелгән календарь кварталның беренче аендагы 1нче көненә идарәче компаниянең әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

идарәче компаниянең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имза куелган, әлеге пунктча нигезендә квартал саен бирелә торган заявка бирелгән календарь кварталның беренче аендагы 1нче көненә идарәче компаниянең «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

идарәче компаниянең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имза куелган, әлеге пунктча нигезендә квартал саен бирелә торган заявка бирелгән календарь кварталның беренче аендагы 1нче көненә идарәче компаниянең үзгәртеп оештыру (идарәче компаниягә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәвен, идарәче компания эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмавын раслый торган белешмә кәгазе;

идарәче компаниянең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имза куелган, әлеге пунктча нигезендә квартал саен бирелә торган заявка бирелгән календарь кварталның беренче аендагы 1нче көненә дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки идарәче компаниянең баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

идарәче компания җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасының унтугызынчы – егерме икенче һәм егерме бишенче – егерме тугызынчы абзацларында күрсәтелгән факттагы чыгымнарны раслый торган документлар исемлеге (эшләрнең тиешле төрләренә шартнамәләр күчермәләреннән тыш).

Әлеге пунктчаның дүртенче абзацы нигезендә идарәче компания тарафыннан салым органының белешмә кәгазе тапшырылмаганда, Министрлык салым

органыннан кирәкле белешмәләрне мөстәкыйль соратып ала.

3.2. Әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән документлар идарәче компания тарафыннан электрон документлар (законнар нигезендә электрон имза белән имзаланган) һәм (яки) кәгазь документлар формасында тапшырылырга мөмкин (идарәче компаниянең сайлавы буенча).

Идарәче компания тарафыннан тапшырыла торган документлар рус телендә эшләнгән булырга тиеш. Өченче затлар тарафыннан төп нөсхәләре чит телдә бирелгән документлар нотариус тарафыннан расланган рус теленә тәрҗемәсе теркәлү шарты белән тапшырылырга мөмкин.

3.3. Тапшырыла торган белешмәләр дөрес булмаган өчен, шулай ук ялган документлар ясаган өчен идарәче компания Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

Барлык тапшырыла торган документларның һәр пункты тутырылган булырга тиеш (мәгълүмат булмаган очракта, сызык куела).

Әлеге Тәртипнең 3.2 пункты нигезендә идарәче компания тарафыннан документлар кәгазьдә тапшырылган очракта:

чистартулар һәм төзәтүләр (вәкаләтле затның имзасы һәм мөһер (булганда) белән расланган төзәтүләрдән тыш) рөхсәт ителми;

ел саен һәм квартал саен бирелә торган заявканың барлык битләренә номер язылган булырга тиеш;

ел саен һәм квартал саен бирелә торган заявкалар тегелгән һәм заявканың соңгы битенең артына, гомуми бит саны күрсәтелеп, вәкаләтле затның имзасы һәм идарәче компаниянең мөһере (булганда) белән расланган булырга тиеш;

әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче – дүртенче, уникенче, унбишенче – унҗиденче абзацларында һәм әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче – дүртенче абзацларында күрсәтелгән документлар идарәче компания тарафыннан Министрлыкка ике нөсхәдә тапшырыла (документларның икенче нөсхәсенә карата әлеге пунктның бишенче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән таләпләр кагылмый).

3.4. Идарәче компания заявканы Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгәнгә кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы.

## IV. Заявкаларны кабул итү һәм карау тәртибе

4.1. Министрлык әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә ел саен бирелә торган заявканы алганда:

ел саен бирелә торган заявканы тиешле журналга Министрлыкка кергән көнне терки, аның теркәлү номерын, вакытын һәм датасын күрсәтә;

ел саен бирелә торган заявканы теркәгән көннән алып ике эш көне эчендә идарәче компаниянең һәм тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында, 3.1 пунктындагы «а» пунктчасында, 3.2 һәм 3.3 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм шартларга туры килү-килмәвен тикшерә;

әлеге пунктның өченче абзацы нигезендә тикшерү үткәрелгәннән соң бер эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы унөченче – егерме дүртенче, егерме алтынчы – егерме тугызынчы абзацларында күрсәтелгән документларны Татарстан

Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына тапшырылган документларның дәүләт экспертизасыннан уңай бәяләмә бирелгән проект (смета) документларына туры килүен раслау өчен җибәрә яки әлеге Тәртипнең 4.5 пункты нигезендә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

4.2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасының унөченче – егерме дүртенче, егерме алтынчы – егерме тугызынчы абзацларында күрсәтелгән документлар Министрлык тарафыннан тапшырылганнан соң, дүрт эш көне эчендә аларны тикшерә һәм тикшерү үткәрелгәннән соң бер эш көне эчендә Министрлыкка тапшырылган документларның дәүләт экспертизасыннан уңай бәяләмә бирелгән проект (смета) документларына туры килүе яисә туры килмәве турында бәяләмә җибәрә.

4.3. Министрлык, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы бәяләмәсен алган көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча, Кагыйдәләргә 5 нче кушымта нигезендә идарәче компаниянең парк инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарының бер өлешен каплау мөмкинлеге турында бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра яки әлеге Тәртипнең 4.5 пункты нигезендә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

4.4. Министрлык әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә квартал саен бирелә торган заявканы алганда:

квартал саен бирелә торган заявканы тиешле журналга Министрлыкка кергән көнне терки, аның теркәлү номерын, вакытын һәм датасын күрсәтә;

квартал саен бирелә торган заявка теркәлгән көннән ике эш көне эчендә идарәче компанияне һәм тапшырылган документларны әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында, 3.1 пунктындагы «б» пунктчасында, 3.2 һәм 3.3 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм шартларга туры килү-килмәүгә тикшерә, тикшерү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, кирәк булганда, әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы өченче һәм унберенче абзацларында күрсәтелгән таләпләргә идарәче компаниянең туры килүе турында мәгълүмат бирелгән кушымта теркәлә;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында каралган максатлар өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия акчасы кергән көннән соң килә торган биш эш көне эчендә һәм әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән беркетмә нигезендә әлеге Тәртипнең 4.5 пункты нигезендә субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, ул боерык белән рәсмиләштерелә.

4.5. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

идарәче компания тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 3.2 һәм 3.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

идарәче компания тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү;

әлеге Тәртипнең 4.7 пункты нигезендә идарәче компанияне субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзүдән баш тарткан дип тану;

ел саен һәм квартал саен бирелә торган заявканың бирү срокларын бозу.

4.6. Әлеге Тәртипнең 4.4 пункты нигезендә идарәче компания тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карар кабул ителгән көннән алып җиде эш көне эчендә идарәче компания белән Килешү төзи.

Килешү түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә ала:

идарәче компаниянең Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүләргә (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

әлеге Тәртипнең 1.4 пунктында күрсәтелгән, Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча Килешүгә ирешә алмаганда Килешүне өзү хакында шарт.

Килешү, Килешүгә өстәмә килешүләр, шул исәптән Килешүне өзү турында өстәмә килешү (кирәк булганда) «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) (техник мөмкинлек булганда) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә төзелә.

Идарәче компанияне кушылу, кушу яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп оештырганда, Килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә Килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, Килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

4.7. Идарәче компания Килешү проектына аны алган көннән соң килә торган өч эш көне эчендә имза куя. Килешүгә имза куюның билгеләнгән срогы үтәлмәгәндә, мондый заявка бирүче Килешү төзүдән баш тарткан дип танылла, Министрлык, әлеге пунктта билгеләгән срок чыккан көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидияләр бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Килешү парк проекты паспорты нигезендә парк проектын гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган срогы белән бер булган срокка төзелә.

## V. Субсидия күләмен исәпләү тәртибе, субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

5.1. Министрлык субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә идарәче компаниянең Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына яки корреспондент счетына күчерә.

5.2. Кире кайтару өчен субсидия бирелә торган чыгымнарның юнәлеше – идарәче компанияләрнең түбәндәгеләр өчен фактта башкарылган һәм документлар белән расланган чыгымнарының бер өлеше:

индустриаль (сәнәгать) паркның инфраструктура объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү;

сәнәгать технопаркы, югары технологияләр өлкәсендәге технопарк

инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү, шулай ук сәнәгать технопаркының, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның технологик инфраструктурасы составында җиһаз сатып алу;

парклар инфраструктурасы объектларын проектлау (проект документациясен эшләү, аңа һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү, паркның капиталь төзелеш объектларын төзүнең, модернизацияләүнең һәм (яки) реконструкцияләүнең смета кыйммәтен билгеләүгә дәүләт экспертизасын үткәрү чыгымнарын кертеп);

парк инфраструктурасы объектларының техник шартларын эшләү һәм (яки) аларны инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә технологик тоташтыру.

5.3. Идарәче компания тарафыннан бирелә торган субсидиянең иң чик күләме (С) (сумда) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$C = \left(\sum_{k=1}^{n} (S1_k + S2_k + S3_k + S4_k) \times 0{,}75 - R\right) \times \varphi_{i-1},$$

монда:

n – парк инфраструктурасы объектлары саны;

$S1_k$ – идарәче компаниянең парк инфраструктурасындагы k объектын проектлауга (проект документациясен эшләү, аңа һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү, паркның капиталь төзелеш объектларын төзүнең, модернизацияләүнең һәм (яки) реконструкцияләүнең смета кыйммәтен билгеләүгә дәүләт экспертизасын үткәрү чыгымнарын кертеп) фактта башкарылган һәм документ белән расланган чыгымнары суммасы;

$S2_k$ – идарәче компаниянең парк инфраструктурасындагы k объектын төзүгә, модернизацияләүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә фактта башкарылган һәм документ белән расланган чыгымнары суммасы;

$S3_k$ – идарәче компаниянең сәнәгать технопаркындагы, югары технологияләр өлкәсендәге технопарктагы технологик инфраструктурасы k объекты составында җиһаз сатып алуга фактта башкарылган һәм документ белән расланган чыгымнары суммасы;

$S4_k$ – идарәче компаниянең парк инфраструктурасы объектларына тоташтыру (технологик тоташтыру), кушылу шартнамәләре нигезендә фактта башкарылган һәм документ белән расланган чыгымнары суммасы;

R – проект гамәлгә ашырыла башланган елның I кварталыннан алып, идарәче компаниягә моңа кадәр бирелгән субсидия күләме;

i – агымдагы календарь ел;

$\varphi_{i-1}$ – Кагыйдәләргә 1 нче кушымтаның 7 нче пункты нигезендә исәпләп чыгарыла һәм, Кагыйдәләрнең 3 пунктында күрсәтелгән парк проекты гамәлгә ашырыла башланган датадан соң 10 елдан да соңга калмыйча, федераль сайлап алуга заявка бирелгән очракта, 1гә тигез итеп алына торган i – 1 чорында парк инфраструктурасын файдалану коэффициенты.

Субсидия идарәче компаниягә квартал саен әлеге Тәртипнең 4.4 пунктындагы дүртенче абзацы һәм 5.1 пункты нигезендә түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган күләмдә ($L_j$) (сумда) бирелә:

$$L_j = \frac{100 \times b_j}{99},$$

монда:

j – календарь квартал;

b – 41 пункт һәм Кагыйдәләргә 1 нче кушымта нигезендә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелгән субсидия күләме.

5.4. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

индустриаль (сәнәгать) парк проекты өчен:

индустриаль (сәнәгать) парк территориясенең 1 гектар гомуми мәйданына парк резидентлары тарафыннан төп капиталга бюджеттан тыш инвестицияләрнең чагыштырма күләме (млн.сум);

парк резидентларын урнаштыру өчен билгеләнгән индустриаль (сәнәгать) парк территориясенең гомуми мәйданына карата парк резидентлары биләгән индустриаль (сәнәгать) парк территориясе мәйданының нисбәте (гектар), процент;

парк резидентлары тарафыннан булдырылган эш урыннары саны;

сәнәгать технопаркы проекты һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарк проекты өчен:

сәнәгать технопаркы, югары технологияләр өлкәсендәге технопарк биналарының, төзелмәләренең 1 кв.метр гомуми мәйданына карата сәнәгать технопаркы, югары технологияләр өлкәсендәге технопарк территориясендә парк резидентлары тарафыннан башкарылган эшләрнең һәм күрсәтелгән хезмәтләрнең, үз җитештерүендәге төяп җибәрелгән товарларның чагыштырма авырлык күләме (мең сум);

парк резидентларын урнаштыру өчен билгеләнгән сәнәгать технопаркы, югары технологияләр өлкәсендәге технопарк биналарының, төзелмәләренең гомуми мәйданына (кв.метр) карата парк резидентлары биләгән сәнәгать технопаркы, югары технологияләр өлкәсендәге технопарк биналары, төзелмәләре мәйданының нисбәте, процентта;

парк резидентлары тарафыннан булдырылган эш урыннары саны.

Әлеге пунктта каралган субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткече һәм аларга ирешү сроклары Килешүдә Кагыйдәләрнең 21 пункты һәм проект паспорты нигезендә билгеләнә.

## VI. Хисаплар бирүгә, субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыруга һәм аларны бозган өчен җавап бирүгә карата таләпләр

6.1. Идарә итүче компания Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү мониторингын гамәлгә ашыру максатларында квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләрен бәяләүне гамәлгә ашыру максатларында ел саен, парк проекты гамәлгә ашырыла торган хисап елыннан соң килә торган елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап.

Әлеге пунктта күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап «Электрон бюджет» системасында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасында күрсәтелгән форма буенча бирелә.

Министрлык, кирәк булганда, Килешүдә идарәче компания тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгеләргә хокуклы.

Министрлык хисаплар тапшырыла торган көннән соң килә торган 10 эш көненнән артмый торган срокта идарәче компания тарафыннан әлеге пункт нигезендә тапшырылган хисапларны тикшерүне һәм кабул итүне гамәлгә ашыра.

6.2. Министрлык әлеге Тәртипнең 6.1 пунктындагы өченче абзацы нигезендә парк проекты паспорты нигезендә парк проекты гамәлгә ашырыла торган 10 нчы елга (15 нче (20 нче) елга (парк проектының гамәлгә ашыру срогы озайтылганда)) субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләрен бәяләү йомгаклары буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында яки ирешмәү турында карар кабул итә:

парк проекты паспорты нигезендә парк проекты гамәлгә ашырыла торган 10 нчы елдан соң килә торган елның 10 февраленнән дә соңга калмыйча;

парк проекты паспорты нигезендә парк проекты гамәлгә ашырыла торган 15 нче (20 нче) елдан соң килә торган елның 10 февраленнән дә соңга калмыйча (парк проектының гамәлгә ашыру срогы озайтылганда).

6.3. Идарәче компания тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәләренең ел саен билгеләнә торган күрсәткечләренең 30 процентына кадәр ирешелмәгән очракта, субсидия бирү нәтиҗәләренең ел саен билгеләнә торган күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшырылганга кадәр чираттагы финанс елына субсидия бирү туктатып торыла. Нәтиҗәләрнең ел саен билгеләнә торган күрсәткечләренә ирешү проценты нәтиҗәләрнең ел саен билгеләнә торган күрсәткечләре санына карата һәр нәтиҗә күрсәткечләренә ирешү проценты суммасының нисбәте буларак билгеләнә. Әгәр календарь елга нәтиҗәнең план буенча күрсәткече нульгә тигез булса яки әгәр нәтиҗәнең фактта ирешелгән күрсәткече Килешүдә билгеләнгән нәтиҗә күрчәткеченнән арткан булса, нәтиҗәнең тиешле күрсәткеченә ирешү дәрәҗәсе 100 процентка тигез итеп алына.

6.4. Әгәр хисап финанс елының 31 декабренә карата идарәче компания тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү буенча йөкләмәләр бозылган һәм субсидия бирелә торган елдан соң килә торган елда Килешү нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирүнең беренче датасына кадәр срок эчендә әлеге бозулар бетерелмәгән булса, идарәче компания субсидия бирелә торган елдан соң килә торган елның 1 маена кадәр субсидияне түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган күләмдә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә кире кайтаруны ($V_{кайтару}$)тәэмин итә:

$$V_{кайтару} = \left(\frac{Vсубсидии \times k \times m}{n}\right),$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында идарәче компаниягә бирелгән субсидия күләме, сум;

m – субсидия бирү нәтиҗәсенең i-күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индексы уңай мәгънәгә ия булган субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре

саны;

n – субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренең гомуми саны;

k – субсидияне кире кайтару коэффициенты.

Субсидияне кире кайтару коэффициенты түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$k = \frac{SUM\ D_i}{m},$$

монда $D_i$ – субсидия бирү нәтиҗәсенең i күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индекс.

Субсидияләрне кире кайтару коэффициентын исәпләгәндә, субсидия бирү нәтиҗәсенең i күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай билгеләре генә кулланыла.

Субсидия бирү нәтиҗәсенең i күрчәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индекс түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$D_i = 1 - \frac{T_i}{S_i},$$

монда:

$T_i$ – хисап датасына субсидия бирү i-нәтиҗәсенең фактта ирешелгән күрсәткече;

$S_i$ – Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү i-нәтиҗәсенең план буенча күрсәткече.

6.5. Идарәче компаниягә карата:

Министрлык аның тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра;

дәүләт финанс контроле органы тарафыннан тикшерүләр Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла;

Россия Сәнәгать министрлыгы, дәүләт финанс контроле органнары, Министрлык тарафыннан субсидия бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешенә тикшерүләр үткәрелә.

6.6. Субсидия идарәче компания тарафыннан Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда тулы күләмдә (әлеге Тәртипнең 6.4 пункты нигезендә идарәче компания тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына элегрәк кире кайтарылаган субсидия өлешен тотып калып) кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен идарәче компания тарафыннан дөрес (тулы) булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылган;

субсидия биргәндә билгеләнгән тәртип һәм шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшырмау.

6.7. Әлеге Тәртипнең 6.6 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамә идарәче компаниягә электрон документ формасында (законнар нигезендә көчәйтелгән квалифи-

кацияле электрон имза белән имзаланган) һәм (яки) кәгазь документта (Министрлыкның сайлавы буенча) җибәрелә.

6.8. Әгәр субсидия (субсидиянең бер өлеше) әлеге Тәртипнең 6.4 һәм 6.6 пунктларында билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган булса, Министрлык тиешле срок тәмамланган көннән соң килә торган 30 эш көне эчендә тиешле акчаны закон белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү өчен мөрәҗәгать итә.

6.9. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәгә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

6.10. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.